
Әткәм
һөнәре
Хәсән Сарьян

ХӘСӘН САРЬЯН

# Әткәм һөнәре

(ПОВЕСТЬ)




БИБЛИ... ЕКА
ТАТ...ИЗДАТА
Инв. № 4146
7069

ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ
Казан 1966

С(ТАТ)2
Х91

Редакторы
Л. Ихсанова

Художнигы
С. Кульбака



Әткәй! Мин сиңә бик аз хәтерлим — төштә генә күргән сыман. Ләкин мине сиңа охшаган диләр, хәтта балта һөнәрең дә миңа күчкән.

Әткәй, Хәсән улы Салихҗан! Синең рухыңа багышлап яздым бу әсәремне.

Автор

## *Беренче бүлек*

Гаяз уянгач, тегеләрнең дә сыңар күзлесе торып утырды. Күзле ягы белән Гаязга борылып:

— Сәгать ничә? — диде.

— Сигез тула.

— Буфет ачык микән, белмисеңме?

— Буфет унда гына ачыла.

— Чатный гына! — диде сыңар күзле һәм аптырау хәлдә идәнгә төште. Башын тавык кебек кыегайта

шып киткән култык таякларын үзенә таба тартып куйды. — Әйдә, кайтасыңмы?

Гаяз утыру белән ул дилбегәне бушатып җибәрде. Ат җиленнән борынга тансык ис килеп бәрелде.

— Машинаң кайда, Сәйдәшев агай?

— Буяткан булган идем... Үзең соң, ничек, отпускагамы?

— Минме? — диде Гаяз. — Мин бөтенләйгә кайттым.

— Сине бит солдаттан соң кайдадыр эшкә урнашкан дип әйткәннәрие?

— Демобилизациядән соң безнең частьтан берәү дә кайтып китмәде. Һәммәбез дә комсомол путевкасы белән чирәм җирләргә киттек. Төпләнеп калучылар да булды. Мин менә кайттым.

— Дөрес иткәнсең кайтып,— диде председатель, ләкин шатланырга ашыкмады, чөнки авыл кешесе, читтә бер йөреп кайттымы, колхозны түгел, заготзерно ягын чамалый торган иде.

— Эш турысында да уйлашырга кирәк булыр инде, Сәйдәшев агай, — диде Гаяз үзе башлап.


— Шулай инде, шулай... Исәпләрең кай тирәдәрәк соң?

— Хезмәттә мин моторизованный частька эләктем. Совхозда да һаман машинада эшләдем. Исәбем колхозда инде, Сәйдәшев агай. Бәлки син дә машина бирерсең?

Председатель шатлыгын сиздермәс өчен айгырын тыя төште.

— Тәртәсе кыскарак. Дилбегәне чәк кенә бушайтыңмы, сажин ярым атларга керешә, тоягын бәрә башлый,— дигән булды. — Бүгеннән генә буш машина юк, юклыкка. Шулай да табарга була. Ийе. Табарга була анысын. Тик яшерен-батырын түгел, апай: бүгеннән мина төзелешкә кешеләр кирәк. Төзелеш күп — осталар эз. Юк осталар! Җиде авылдан көчкә иллалла җиде





бригат этмәләдек. Халык та — һәркайсы йорт җиткезә. И шуннан уйла инде: әз генә балта тота белгәне дә көйләтә, апай. Чыктым киттем белән куркыталар. Сезнең Кави белән шулай булмадымыни. Ярый инде, Кавие — Кави. Ул, ни әйтсәң дә, оста! Чыпчык Сәмих ишеләре дә бар бит әле анын. Беләсең син аны, сельмагта сатучы иде. Кайсы үз аягы, кайсы бүрәнә икәнен бутый торган бер бәндә иде. Син юкта өстенә чыгып, төрмәдә дә утырып кайтты. Шунда әзрәк балта тоткан бугай. Хәзер нәстә эшләй диген? Йорт сөйләшеп чыгып киткән. Җыгыл да үл! Һа-ай Сөләйман абзыйны терелтәсе иде! Эшләмәсение. Карап кына торсыние... Юк, кайтыр җирләргә китмәде,— Сәйдәшев башын чайкап, телен шартлатып алды.— Мәрхүмгә илле чакрымнан килерләрие. Колхоз рөхсәтеннән башка шаг та атламасие. Ә хәзергеләр нәрсә?.. Карап торган бер Кавиебыз бар иде. Ул да тәртәгә типте. Локман абзый котыртты. Иблис дисәм — сезнең зат...

— Син монда кереп, төпчек абзый, колхозны яманлап утырма, яме! — диде. — Эткәй тезегән колхоз ул!..

— Без дә төзедек аны, — диде Локман. — Тик без төзегәне юк хәзер. — Аннары ул, тавышсыз гына көлеп: — Абзыйның да кызыл чаклары бар иде мәрхүмнең, — дип куйды.

Кинәт Таһир йөрәктәге бар булган канының беләкләренә сава башлавын тойды. Әгәр Локман урынында икенче берәү булса — яралы арсландай ташланыр да бугазын чәйнәр иде. Ләкин ярсу беләктән чыкмады, җыела гына башлаган күз яшедәй, тамакка килеп тыгылды. Шул хәлендә ул Локманга текәлеп калды. Локман тетрәнеп куйды: бу караш иртән үзе тавык суйган пычак йөзедәй зәһәр иде. Әмма Таһир үзенең берешә башлавын сизде: яшькә ике тапкыр, көчкә ун тапкыр өстен торган кан кардәшенә каршы тора алмый иде инде ул. Шулай да соңгы көчен җыеп:

— Эткәй колхоз өчен кан койган, шуңа кызыл булган! — диде һәм буылып ютәлләргә тотынды.


Ул берешә, аны җиңделәр, аны Локманнан алда чир җиңде. Ул өстәл янынннан торып, урынына барып ятты. Чир өстенә ни әнисенең, ни Гаязның яклап сүз әйтмәве аны рәнҗеткән, аяктан еккан иде. Бер тазалыгың киткәч, үзеңнекеләр дә санга сукмый икән, диде ул.

Инде Локман Таһирның ютәл өянәгеп гадәти хәлгә санап, аңа күз дә ташламастан, Гаязга карап дәвам итте:

— Менә шул, Әбел-Гаяз, үзең хәл ит. Дөньяны син көтәсе. Синең өстә үзең белән өч җан.

Гаяз уйга калды. Ул инде баядан бирле уйлый, аның башына бая төпчек абзыйларында утырганда ук уй төшкән иде. Узган ел, совхозда эшләгәндә, ике-өч тапкыр акча җибәрүен исәпкә алмаганда, ул әле дөнья көтүнең ни икәнен дә белмәде. Дөньяны картайганчы






этисе көтте. Хәзер ул көтәргә тиеш... «Әллә юкса чынлап та төпчек абзый белән эшләп алыргамы?» диде ул күңеленнән. Сәйдәшев бүгеннән генә кыстап бармый бит. Берәр атна ял ит әле, диде. Берәр атнасын ял исәбенә эшләсәм, икенче атнасын өстәп сорармын. Аңлар. Аңламас кеше түгел. Аннары төпчек абзыйсы, этисеннән кала, тирә-якта беренче остадан санала иде, аның янында ун-унбиш көн эшләп алуның файдасыннан башка нәрсәсе булмаска тиеш.

Гаяз Таһирга карады. Абыйсы ике кулын баш астына салып яткан да күзләрен түшәмгә текәгән, гүяки аның

— Гаяз!.. Син түгелме соң? — диде.
— Мин, Халидә. Мин... — диде Гаяз.
— Тәрәзә аша күрешмик инде. Кер бу якка әнә шул ишектән, — диде Халидә һәм үзе дә ян ишеккә юнәлде.
Гаяз залдан чаршау белән генә бүленгән коридорга керде һәм каршында елмаеп торган Халидәнең уттай кайнар кулын кысты. Халидә аның кулын җибәрмәде, «Әйдә монда» дип, кухня каршындагы бүлмәсенә алып кереп китте. Бу бүлмәнең тәрәзәсе зур, эче тулы кояш иде. Халидә егетнең икенче кулыннан да тотып алды һәм шулай, каршына баскан килеш, әз генә башын күтәрә биреп, Гаязның күзләренә карады; шунда аның төпсез күзләренә яшь тулып, иреннәре калтырый башлады.
— Халидә!— диде Гаяз. Үзен үзе белештермичә аның калтырап торган гәүдәсен кочаклады.
Халидә барыбер тыела алмады — елап җибәрде.
— Нигә инде, Халидә?.. Нигә?..
— Нигә буламыни? Сагынганга... — диде Халидә. — Сагынганга җылыйм, Гаяз...
Шунда ишек шакыдылар. Халидә тиз генә Гаязның кочагыннан чыгып, арткарак чикте. Ишектән, кер дигәнне дә көтмичә, Гаязга аш бүлгән кыз килеп керде.
— Менә, абый, сезнең ашлар, — диде ул. Подносны өстәлгә китереп куйды.
— Утыр, Гаяз, — диде Халидә һәм үзе дә аның каршысына утырды.
— Кайчан кайттың? — диде ул бераздан.
Гаяз аңа әкрен генә җавап бирде.
— Я, безнең ашларны да ашап кара, — диде Халидә.
— Инде ашыйсым да килми, — диде Гаяз. Шулай да теләр-теләмәс кенә ашый башлады.
Улына сөеп караган ана кебек, Халидә аңардан күзен дә ала алмый иде.





Гаяз ярты гына тарелка аш ашады да кашыгын читкә үк куйды.
— Безнең ашны яратмадың ахры? — диде Халидә.
— Аш бик тәмле, ашыйсым гына килми.
— Таһирҗанның хәле ничек соң?
— Хәзергә бераз әйбәт әле.
— Авылга бүген үк кайтып китәсеңме?
— Бүген үк китәм. Төпчек абзый белән бер эш алган идек.
— Нинди эш? — диде Халидә.
— Кичә Нухка өй сөйләштек.
Халидә кинәт үзгәреп китте, әле генә балкып торган



ишеткән саен, җырларын искә төшергән саен, күз алдына да гел әнә шул, бүгенге Кудашева килеп басачак. Һәм Гаязның аны башкача итеп («я хәзер тездән кыска күлмәк кигәндер әле ул») күрәсе килмәде, шуңа, артистлар фойедан үткәндә дә, бер читтәрәк торды.

Земфира озак көттермәде. Алар клуб карачуы апа белән бергә чыктылар. Янып калган утларга күрсәтеп, ул аңа нидер аңлатты да туп-туры Гаяз янына килде. Килешкә үк:

— Әнә тегендә бер егет тора, арттан иярсә-нитсә, әллә нәрсә уйламагыз, — диде.

Арты белән баскан ул егетне Гаяз күз кырые белән генә бая ук шәйләп алган иде. Ләкин, халык чыгып бетсен әле, дип көтеп торучылар бер ул гына булмаганга,



игътибар итмәде, Земфира әйткәч кенә борылып карады, һәм шунда нигәдер, ярамас эшкә тотынгандай, эче пошып китте — стена буенда Флүс басып тора иде.

Алар чыгарга юнәлделәр. Флүс тә сөялгән стенасыннан аерылды.

— Калмас инде ул! — диде Земфира.

Флүснең калу исәбе юк иде. Ул бүген, кичә генә алган костюмнарын киеп, Земфираны озатып куярга җыеныл килгән иде. Их, озаттырсамы?.. Бүген инде ул җибеп тормас иде — биленнән генә (монысын хәтта тез буыннары каты килеш уйлап та булмый) менә шулай итеп кысып алыр иде дә... Үптермәсен дә ди, әйдә...

Ул концерт алдыннан Земфира янында буш урын күргәч: «Миңа алып куйганмы әллә?» — дип, бөтенләй каушап төште. Ләкин Земфира, кешесе бар гына диде.

Менә кем булган икән аның кешесе! «Бу сине, апаем, биленнән генә кысып калмас — бу сине май йомарлагы итәр. Ух!.. Үз тиңем булсамы — мин аның белән ничек сөйләшергә белер идем. Әллә?.. Юк, моны җиңү — айяй! Кави абзый төсле дә булса...» Флүс, көнләшүдән каралай көеп, тешләрен кысты, янсын әйдә дип, тәмәке кабызды.

Алар урамда иде инде. Яктыдан караңгыга чыккач, Земфиралар чокырга төшеп киткәндәй булдылар. Флүснең иң курыкканы шушы иде. Ул: «Китәләр, калам бит!» — дип уйлады һәм, китк әнне тәмәке төтенедәй суырып алырга җитеп, төн карасына дәште:

— Земфира!..

— Менә, әйткән идем бит! — диде Земфира һәм, Гаязга бара торырга кушып, тәмәке утына каршы китте.

— Нигә кычкырасың инде, Флүс? — диде ул.

— Земфира... Бер генә сүз.

— Я, нәрсә?

— Тыкрыктан соң да ул озатамы?

Ул, ут яндырып, ишекне ачып җибәрде — ишек авызыннан киңәеп җиргә төшкән ут яктысында кызы белән ул басып тора иде.

— Кайттыгызмы? — диде Нух.

Земфира, куркып ук китеп:

— Әткәй, синме бу? — диде.

— Мин лә ул... — диде әтисе.

— Ятмадыгызмыни әле?

— Яткан идек лә. Минә эчемә әллә нәрсә ярамады.

Ул, күтәрмәдән төшеп, караңгыга кереп югалды, ә үзе, тынычланып: «Ярар, башы булды, бакасы булыр»,— дип куйды.


## *Уникенче бүлек*

Локман карт эсседә башына яулык бәйләп эшли; өскә шуып менмәсен өчен, ул аны маңгай астыннан ук бәйләп куя, яулык читеннән ике күзе генә кысылып күренеп кала; көн буена әкрен генә чыккан маңгай тире күзгә агып төшми, яулыкка сеңә барып, маңгаена рәхәт салкынлык биреп тора. Күлемгә туктаган саен, ул аны киптереп ала, һәм һәрвакыт, яулыгын чишү белән, кыскарып беткән каләме колак өстеннән төшеп китә. Ул беренче көнне үк Гаязга да яулык бәйләргә киңәш итте.

— И, күлмәгеңне дә салып эшләргә өйрән. Тәнең кояшка янсын, карайсын. Егетләргә шалкан төсле тән килешми.

Гаяз күлмәген салса да, яулык бәйлә дигәнгә, «Ярый болай да» дип, кул гына селтәде. Барысы да яулык бәйли башласа, иллә мәзәк булыр иде тегеләй!.. Ул яланбаш кына эшләргә булды. Барак салучылар да әнә яланбаш эшли, бер Кави гына кепкасын батырып кигән иде.






— Син аларга карама, — диде төпчек абзыйсы. — Тир түгеп эшләмиләр алар. Көн узсын дип кенә эшлиләр.

Ул өй салуның акчасын гына түгел, үзен дә сагынган иде, баштагы көннәрне хәтта ял итеп тә тормады. Гомумән, Локман карт кабызып җибәрелгән машина кебек эшли, туктаганда үзе дә:

— Ярар, машинага да ял кирәк, — дип туктый иде.

Алар өйләгә чаклы бер, өйләдән соң бер-ике генә тапкыр күлем ясыйлар, анысында да Локман ун-унбиш минуттан артык утырырга ирек бирми:



уйлаган иде. Кайтып балта чапкач, андый уе кителеп кенә төшкәндәй булды.

«Шулай да «матай» алганда ярый»,— диде ул. Ишек төбендәге кешеләрнең, таскак башындагы пожарникның карап торуын тойган хәлдә, кайтыр якка борылды.

Культура йорты шул ук урамда иде. Килгәндә ул аны үтеп кенә киткән иде, әле туктап, кереп чыгарга булды.

Фойеда бүген беркем дә юк икән, бильярд өстәле дә, дүрт аяклы мал кебек, бер почмакта тора.

Земфира бүген икенче кызлар белән иде.

Гаяз, ишектән атылып керү белән, шатлыгына ирек куеп:



— Кайтасыңмы, Земфира? «Матай» белән генә алып кайтам үзеңне! — диде.

Кызның бите яна башлады. Ак чырайлы булганга, ул тиз кызара иде: бит очлары алсу булып янып та чыкты. Ул, сәгатенә караган булып, йөзен түбән иде.

Гаязның шат күңеле кызларга да күчте. Алар:

— И малайкайлар! Төш тә житкән бит! — дип, җыена да башладылар. Земфираны шул коткарды да. Ул йөзен сәгатьтән алды.

— Кызлар, төштән соң килергә онытмагыз! — диде.

Алар бүлмәдән бөтенесе бергә чыктылар. Кызлар бер-берсен авылча култыклап, тезелешеп, Земфираның мотоциклга бик җайсыз утырганын карап тордылар. Кызның итәге кыска иде: утыргач, бигрәк тә, өскә шуып менеп китте. Иптәшләреннән берсе, аңа дәшеп, кулы белән күлмәгенә күрсәтте. Земфира калкынып, итәген тарткалап карады — барыбер җибәрмәде.


— Булдымы? — диде Гаяз.

Мотоцикл әкрен генә кузгалып китте. Кызлар:

— Әйләнеп төшә күрмә! Гаяз абыйга нык ябеш! — дип кычкырып калдылар.

Аларга артезиан коесыннан су алучы хатын-кызлар да карап калды.

«Иртәгә сөйли башлаячаклар,— дип уйлады Земфира.— Юк, бүген үк. Иртәгә авылга ук таралачак.— Ул инде ник утырганына үкенә дә башлады.— Юкка утырдым... Халык теленә генә кереп калам инде... Мотоциклына да утырып йөргән булган иде, егетнең исе китмәде, башлады да ташлады, диячәкләр. Әйдә, дисеннәр! Әйтсәләр дә, барысы да кызыгып, көнләшеп карап калды әле... Башлады да ташлады?.. Чынында, башлау юк — ташлау да булмаячак иде. Башламагач, ташлыйлар микәнни?.. Ул Халидә апаны ярата...»



алмаганнарның да үчен кайтарыйм, ичмаса: сине генә яраттым, Халидә! Сине генә, сине генә! Ышанасыңмы?

Халидә аның күзләренә карады һәм әкрен генә:

— Ышанам...— диде.

— Ышансаң, иртәгә үк барып эшеңнән чык. Кайт үзебезнең авылга... Кайтасыңмы?

— Аһ, Гаяз! — диде Халидә.— Сөйләп бетермәдем бит әле. «Бетмәгән Зәкиев булды инде», дип уйлый күрмә тагын.

— Төкер шул Зәкиевнең башына! Тагын бер бәйләнсә, чап та җибәр берне яңагына — күзеннән утлар чәчрәп чыксын.

— Алай гына булса икән! Мине ул хәзер, болай җиңәлмәгәч, куркытып җиңәргә итә,— дип, Халидә ашха-



нәдәге хәлләрне сөйләп алып китте: — Шулай икенче сменада эшләүче поварның биш көн эчендә ике йөз илле сумлык продукты җитми чыкты. «Сдача-передача вакытында андый гына җитмәүчелек була инде ул, аларны шулай бер-беребезгә язышырбыз, соңыннан списать итеәл ул», ди. Без аның белән дус эшләдек, мин аңа ышандым. Алдым дип, ике йөз илле сумны да описькә керттем. Ә бүген, аның үзенә тапшырырга чират җиткәч, ул бу сумманы описькә алмыйм, ди. «Списаниегә общий акт төзелгән, Зәкиевтә», ди. Мин Зәкиев янына кердем, ул миңа төрле число белән язылган биш-алты акт сузды. Аларда продуктларның кайсы бозылган, кайсы чучкаларга ашатылган дип язылган. Барлыгы 1414 сум списаниегә кертелгән. Чәчләрем үрә торды. «Зәкиев абый, мин моңа кул куя алмыйм», дидем. «Уйла,— диде миңа Зәкиев,— аның ике йөз илле сумы синең өстә»,— диде. «Минем өстә була алмый ул,— мин әйтәм.— Факия апаның җитмәүчелегенә кул гына куйдым. Әнә үзе монда, үзеннән сорыйк алай булгач», дим. Факия апаны чакырып алып кердем. Ләкин ул Зәкиев алдында баш тартты. Ачуымнан икесен дә өзгәләп ташларга җитешеп өстәлгә суктым: «Барыбер куймыйм! Өскә чыксын — бергә түләрбез. Төрмәгә япсыннар — бергә утырырбыз, күңеллерәк булыр!..» — дидем дә чыгып йөгердем. Сабирҗан китмәгән иде — шуңа утырдым да кайтып киттем.

— Ул акчаны кайтарып бирергә буламы? — диде Гаяз.

— Каян табасың ул хәтле акчаны?

— Үзем бирәм!

— Рәхмәт, Гаяз...— диде Халидә.

Аның өстеннән тау төшкәндәй булды. Ул үзенең бәладән генә түгел, Зәкиевтән дә котылуын сизде. Моңа хәтле дә ул, Зәкиев бәйләнә башлагач: «Бу гарьлеккә



— Сорама да, нитмә дә. Берсе белән дә сөйләшмәячәкмен!

— Алай булгач, бир ачкычларын. Берәр җаен үзем табармын әле...

Гаяз аның күз төбенә йодрыгын китерде:

— Менә — ачкычлар! Агач урлаулары җитмәгән — еще тегесе сугышырга итә. Ул карсак шоферга менә яңакны күгәрткәне өчен дә әләгә әле.

— Башымны бетермә, апай! Нәрсә кирәк, әйт: акчамы? Бирәм. Менә. Кызым кирәкме? Өйлән генә, ризамын. Ул сине ярата да...

Гаяз аның сүзләрен исе-акылы китеп тыңлап торды. Шунда кинәт аның күзен кара кан баскандай булды.



Һәм, үзен үзе тыя алмыйча, Нухның бугазыннан борып алды.

— Җибәр, апай, нишләвең бу?.. Апай, нишләвең бу? — диде Нух. Ләкин үзе тамчы да карышмый иде.

— Синдә эшләгәннән бирле кемнеңдер якасыннан, менә шушылай тотып, җиргә орасым килеп йөри иде — үзең булгансың икән,— диде Гаяз.

Аның тавышына өйдән Таһир килеп чыкты.

— Суга күрмә, апай, суга күрмә берүк! — дип ялына башлады.

— Курыкма, бәлкабзый,— диде бераз басыла төшкән Гаяз.— Мин аңа сукмыйм: суксам, үтермәсәм дә, имгәтәм бит мин аны.

— Алай булгач, җибәр. Нигә җибәрмисең?

— Юк. Бераз селкетим әле: әзрәк пычрагы коелсын.

Ул Нухны кинәт үзенә тартты, аннан кинәт этәреп җибәрде, тагын үзенә тартты, тагын этәреп җибәрде. Нух шулай, көзге яфрактай, бер минут чамасы селкенеп торды.

— Инде ычкын! — диде аңа Гаяз.

Һәм төсе качкан Нух бер пачка акчасын кысып торган килеш чыгып китте.

## *Соңгы бүлек*

Иртән сәгать тугызга Мамлиев Кави бригадасын конторага чакыртып алды. Уфада өч көн булып, кичә бик соң гына кайтып төшкән ул. Кичтән өлгермәсәләр дә, бүген таң белән үк аңа Кави бригадасының инде ике көн эшкә чыкмавын җиткерделәр. «Көн буе райсоюзга сал чыгарып, ике төн эчеп йөрделәр»,— дип әйттеләр.

Мамлиевның Уфадан алып кайткан кызулыгы бетмәгән иде әле, аягүрә басып, каршында тезелешеп утырган

Хасанов Сарьян Салихьянович

ПРОФЕССИЯ ОТЦА

(на татарском языке)

Художество редакторы Б. М. Әлменов

Техник редакторы С. Г. Әхмәтҗанова

Корректоры Р. С. Хәмидуллина

Наборга бирелде 5/V-1966 ел. Басарга кул куелды 18/X-1966 ел. ПФ 07183. Типография кәгазе № 2, $70 \times 108^{1}/_{32}$. Учетн.-изд. табагы 7,51. Басма табагы 6(8,4). Тираж 15000. Заказ № Н-684. Бәясе тышлыгыннан башка 22 тиен, тышлыгы 6 тиен.

ТАССР Министрлар Советы каршындагы Матбугат идарәсенең Камил Якуб исемендәге матбугат комбинатында басылды. Казан, Бауман урамы, 19.

Бәясе 28 тиен

ТАТАРСТАН
КИТАП
НӘШРИЯТЫ
1966